# ГРАЖДАННАР ҖЫЕНЫ КАРАРЫ

**№ 2** **31.10.2025 ел**

Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Чубар-Абдул авыл җирлегенэ керүче Мәндей авылында 2026 елда үзара салым жыюны кертү турында

«Гавами хакимиятнең бердәм системасында җирле үзидарәне оештыруныңгомуми принциплары турында» 2025 елның 20 мартындагы 33-ФЗ номерлыФедераль законның 45, 69 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарәтурында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан РеспубликасыЗаконының 35 статьясы, Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районының Чубар-Абдул авыл җирлеге Уставы нигезендә,Республикасы Азнакай муниципаль районы Чубар-Абдул авыл җирлеге Мәндей авылында халык җыены карар бирә:

1. «Сез 2026 елда Чубар-Абдул авыл җирлеге Мәндәй торак пункты территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган,
- 1 төркем инвалидларыннан,
- көндезге уку формасында укучы студентлардан,
- махсус хәрби операциядә катнашучылар, аларның гаилә әгъзаларыннан,
- Россия Федерациясе Кораллы Көчләрендә хәрби хезмәт узучы

гражданнардан тыш 500 сум күләмендә үзара салым кертү һәм бу акчаларның җирле әһәмияткә ия булган түбәндәге сорауларны хәл итүгә юнәлтү белән килешәсезме:

- һәйкәлләрне (Россия Федерациясе халыкларының мәдәни мирас объектлары (тарих һәм мәдәният һәйкәлләре) булмаган) төзү, ремонтлау һәм аларга якын территорияне төзекләндерү (Мәндәй авылында Бөек Ватан сугышында һәлак булганнарга һәйкәл кору һәм янындагы территорияне төзекләндерү)
- торак пункт чикләрендә гомуми файдаланудагы җирле әһәмиятле автомобиль юлларын төзү, ремонтлау, карап тоту (Ялантау ур., Яңа ур., Тукай ур., Яшләр ур. буенча грейдер белән юлларны тигезләү)
- торак пунктның башка территорияләрен төзекләндерү (Мәндәй авылы юлларын һәм территорияләрен кардан,

500 сум күләмендә үзара салым кертү.

2. Бу акчаларның җирле әһәмияткә ия булган түбәндәге сорауларны хәл итүгә юнәлтү:
- һәйкәлләрне (Россия Федерациясе халыкларының мәдәни мирас объектлары (тарих һәм мәдәният һәйкәлләре) булмаган) төзү, ремонтлау һәм аларга якын территорияне төзекләндерү (Мәндәй авылында Бөек Ватан сугышында һәлак булганнарга һәйкәл кору һәм янындагы территорияне төзекләндерү)
- торак пункт чикләрендә гомуми файдаланудагы җирле әһәмиятле автомобиль юлларын төзү, ремонтлау, карап тоту (Ялантау ур., Яңа ур., Тукай ур., Яшләр ур. буенча грейдер белән юлларны тигезләү)
- торак пунктның башка территорияләрен төзекләндерү (Мәндәй авылы юлларын һәм территорияләрен кардан чистарту)

3. Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми

порталында, кабул ителгәннән соң, 10 көннән соң, соңга калмыйча түбәндәге веб-адрес буенча: http://pravo.tatarstan.ru, Азнакай муниципаль районының рәсми сайтында Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре порталында «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә түбәндәге адрес буенча: http://aznakaevo.tatarstan.ru. һәм түбәндәге адрес буенча урнашкан мәгълүмат стендларында урнаштырырга: ТР, Азнакай муниципаль районы,Мәндәй авылы, Ялантау урамы, 36б йорт.

Гражданнар җыенында рәислек итүче,
Чубар-Абдул авыл җирлеге башлыгы: Н. Ә. Фәтхетдинов